Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының егерме өченче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

7 июль, 2022 ел № 169

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитет структурасы турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясенең «Татарстан Республикасы муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең структурасын булдыру һәм штат санын билгеләү буенча методик тәкъдимнәр турында» 2020 елның 9 декабрендәге ПР-187 номерлы карары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының кушымтада бирелгән структурасын расларга.

2. Түбәндәге Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарларының үз көчен югалтуын танырга:

- «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты структурасы турында» 2005 елның 29 декабрендәге 26 номерлы карары;
- «Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты аппараты структурасына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнары аппаратларында муниципаль хезмәт вазыйфалары санын һәм исемлеген раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 221 номерлы карары;
- «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 14 ноябрендәге 64 номерлы карары.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының расланган структурасы нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар 2022 елның 1 августыннан үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов

Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы Советы карары
белән расланды
07.07.2022 ел № 169

# Татарстан Республикасы
# Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты
# СТРУКТУРАСЫ

| № п/п | Вазыйфаның атамасы | Вазыйфалар саны |
|---|---|---|
| **Җитәкчелек** | | |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 1 |
| 2. | Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | 1 |
| 3. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 3 |
| 4. | Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче | 1 |
| 5. | Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе | 1 |
| **Икътисад бүлеге** | | |
| 6. | бүлек башлыгы | 1 |
| 7. | әйдәп баручы белгеч | 2 |
| **Мәгариф бүлеге** | | |
| 8. | бүлек башлыгы | 1 |
| 9. | бүлек башлыгы урынбасары | 1 |
| **Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге** | | |
| 10. | бүлек башлыгы | 1 |
| 11. | баш белгеч | 1 |
| **ЗАГС бүлеге** | | |
| 12. | бүлек башлыгы | 1 |
| 13. | әйдәп баручы белгеч | 1 |
| **Архив бүлеге** | | |
| 14. | бүлек башлыгы | 1 |
| 15. | әйдәп баручы белгеч | 1 |
| **Мәдәният бүлеге** | | |
| 16. | бүлек башлыгы | 1 |
| 17. | әйдәп баручы белгеч | 1 |
| **Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге** | | |

| | | |
|---|---|---|
| 18. | бүлек башлыгы | 1 |
| 19. | баш белгеч | 6 |
| 20. | әйдәп баручы белгеч | 1,5 |
| **Опека һәм попечительлек бүлеге** | | |
| 21. | бүлек башлыгы | 1 |
| 22. | баш белгеч | 2 |
| **Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе** | | |
| 23. | бүлек башлыгы | 1 |
| 24. | баш белгеч | 1 |
| **Җәмәгать тәртибен саклау пункты** | | |
| 25. | баш белгеч | 1 |
| **Административ комиссия** | | |
| 26. | җаваплы секретарь | 1 |
| **Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлеген техник тәэмин итүне гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәт вазыйфаларына карамый торган вазыйфалар** | | |
| 27. | 5 разрядлы машина йөртүче | 1 |